Токранова Э.И.
“2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”МГББУ
Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы

# Р.ФӘХРЕТДИНОВНЫҢ ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ АША ТӘРБИЯВИ МАКСАТКА ИРЕШҮ

Кеше үзенең хатасын заманага йөкләтә. (Риза Фәхретдинов) [1:139]

21 гасыр буйлап барганда халкыбыз, телебезне саклап калу турында еш сөйләшәбез, әхлаклылыкны үстерү юлларын белемнән дә, тәрбиядән дә, диннән дә кабат-кабат эзлибез. Укучылар белән әдәбият тарихы курсын үткән саен (9-11 сыйныфлар) бу мәсьәләләрнең тарихыбызда күп тапкырлар беренче планга чыгуын күзәтергә була. Тәрбияви әңгәмә вакытында үткән заманда барган вакыйгаларга таянып борынгыларның әхлаклырак, әдәплерәк булуын үзебез дә сизмичә укучылар аңында ныгытабыз кебек.  Укучының фикерен дәвам итеп “элек барысы да яхшы булган, хәзер заманасы начар, якын-тирәдәге кешеләр начар, шуңа күрә барлык явызлыклар безнең заманда...”дип уйламас дип кем әйтә ала? Әлеге ялган фикергә кереп китмәү өчен әдәбият курсында  һәр заманның уңай вә тискәре геройлары булган әсәрләрне өйрәнү кирәк.

XIX гасыр ахыры- XX гасыр башы әдәбиятын өйрәнгәндә шул чорның реалистик прозасы әсәрләре белән укучыларны таныштыру объектив бәяләү өчен бигрәк тә әһәмиятле. З.Бигиевның “Меңнәр...”, “Зур гөнаһлар”, Г.Исхакыйның “Теләнче кыз”, “Кәләпүшче кыз”, Р.Фәхретдиновның “Әсма, яки гамәл вә җәза”, “Сәлимә, яки гыйффәт” әсәрләре шундыйлардан.

Татар әдәбиятының борынгы чорларын инде өйрәнгән укучы әдәбият нигезендә гуманизм идеясе ятуы белән инде таныш. Шуңа да мәгърифәтчелек реализмы һәм реализм арасында яшәүче югарыда әйтелгән әсәрләрнең идеясен үзләштерү укучыга җиңел бирелә. Яңарыш чорыннан (К.Гали “Кыйссаи Йосыф”) килгән “яхшылыкка- яхшылык, яманлыкка- җәза” принцибы “Әсма, яки гәмәл вә җәза” әсәрендә аеруча калку тәкъдим ителә. Г.Исхакыйның “Теләнче кыз”, З.Бигиевның “Зур гөнаһлар” әсәрләрендә дә шул ук әхлак

мәсьәләсе, яшәеш хакыйкате алга куела. “Әсма...” әсәрен анализлаганда Габбас гаиләсенә килгән золымнар Хикмәт хаҗиның үчлегеннән икәненә басым ясау зарур. Югары сыйныф укучысы шәхесара мөнәсәбәтләрнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын бәяли алырга сәләтле инде. Яшьлек вакыйгасы- Габбасның Хикмәт кызына өйләнмәве- вакыйгаларның шундый юнәлеш алуына китерә. Тик мәгънәсез үчлек киләчәктә Хикмәтнең тормышы фәкыйрьлектә үтүгә сәбәпче була. Зәйнүш абыстай да кызларның язмышын хәл итәргә алынганы өчен җәзалы. Ә менә Габбас, Әсма, Сәлимнәргә Аллаһ рәхмәте иңә, сабыр, чиста күңелле булулары, килгән авырлыкларга баш имәгәннәре өчен алар бәхеткә ирешәләр.

Әлбәттә, Әсма образына аерым тукталу кирәк. Чөнки ул төп героиня гына түгел, укучыларның яшьтәше дә. Саф, чиста, сабыр, гадел булса да, ул бу тормышта күп михнәтләр күрә -  эти- әнисеннән аерыла, тәртипсез хатыннар кулына эләгә, аягын сындырып сырхауханәгә эләгә... Тик саф алтынга пычрак ябышмаган кебек, авырлыклардан да үзгәрмичә чыга ала, намусын, гыйффәтен югалтмый. Төшенкелеккә бирелүче, дәресләргә әзерләнмәүләрен өйдәге халәткә сылтаучы, аз гына тормыш каршылыгына очрау белән (начар билге, җавапсыз мәхәббәт) үз гомерләрен чикләүче үсмерләрне мисалга китереп, Әсма язмышы белән чагыштыруның нәтиҗәсе булыр, безнеңчә. “Тугрылык- максатка бара торган юлларның һәм кыскасы, һәм яхшысы,”- дигән Р.Фәхретдинов. [1:175]

Риза Фәхретдинов әсәрләрендә күтәрелгән тагын бер мәсьәләне укучыларыбыз өчен искәртү әһәмиятле. Ул- “милләт анасы” идеясе. “Адәм балаларының бәхетләре- хатыннар кулында,”- ди Риза хәзрәт. [1:224]  XIX гасыр ахыры- XX гасыр башы әдәбияты өчен өчен бу тема аеруча актуаль. Шагыйрь С. Рәмиев тә: “...Туг яңадан, мәгърифәтле анадан,”- дип искәртә “Таң вакыты” шигырендә. Мәгълүм чорда иҗат ителгән С.Рәмиев, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан әсәрләрендә ир-егетләрне дә әйдәп барырга сәләтле актив хатын-кызларны күрәбез. Р.Фәхретдиновның Әсмасы да мөгаллимә булып китте.

Авторның икенче бер романы “Сәлимә яки гыйффәт” романында төп героиня укымышлылыгы, гыйффәте белән үз заманы өчен генә түгел, бүгенге көн яшьләре өчен дә идеал. Университет белемле, туган теленнән тыш гарәп, француз, инглиз телләрен камил белә, хуҗалык алып бару, кул эшләре һөнәрләренә дә оста. Дөньяларын онытып кайсыдыр егетне үзенә каратырга омтылучы кызларга менә дигән үрнәк түгелмени? “Гыйффәт” сүзенә басым ясап аңлату да, һәм югарыда әйтелгән сыйфатлар аңа насыйп ярын табарга ярдәм итүен дә искәртү кирәктер.  Әсманың да, Сәлимәнең дә уртак сыйфаты- үз максатларына туры баруы, идеалларына тугъры булуы. Әлеге сыйфатлары белән алар үзләренә яхшы күңелле кешеләрне җәлеп итәләр.

“Күңелне үзенә тартучы нәрсә- кешенең яхшы холкы белән яхшы гадәтләредер,”- ди Риза Фәхретдинов. [1:253]   Бу кыйммәтләр әхлаклылык нигезен тәшкил итә дә инде. Ә әхлаклылык ул татар халкын калганнардан аерып тора торган сыйфат булу белән беррәттән, халкыбызның даими омтылышы да. Безнеңчә, Риза Фәхретдиновның “Әсма, яки гамәл вә җәза”, “Сәлимә, яки гыйффәт” әсәрләре аша без укучыларга үрнәк алырдай геройларны күрсәтә алабыз, ә тискәре геройлар әхлаксызлык заманга бәйле түгел икәнлекне дәлилли.

Гаяз Исхакый “Мөфти хәзрәтләре вафат” мәкаләсендә “Мөфти хәзрәт үлде. Аның милли, дини  рухы безнең берлә калды. Милләтемез яшәгәнчә ул яшәячәк, ул вакыты килгәндә үзенең вазифасын үтәячәк,”- дип яза.[3:175] Әйе, без яшәргә омтылучы, дин, тел өчен көрәшүче, халкыбызның яшәргә тиеш һәм сәләтле икәнлеген исбатларга мәҗбүр милләт,  һәм Риза Фәхретдиновның рухы, киңәш-теләкләре безгә бүген аеруча кирәк. Әйдәгез, булган хәзинәбезне урынлы файдаланыйк.

Әдәбият

1. Дөньяда сүзем калыр: татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары/ Төз.:Г.Ә. Нәбиуллина, Л.Г. Гыйләҗева.- Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.- 423б.

2. Миңнегулов Х. Гасырлар өнен тыңлап.../ Х.Миңнегулов.- Казан: Мәгариф 2003.-336 б.
3. Ризаэддин Фәхретдин: фәнни-биографик җыентык. /Төз.:Р.Мәрдәнов, Р.Миңнуллин.-Казан, “Рухият” нәшрияты, 1999.-223 б.